Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары

КАРАР

**10 ноябрь 2021 нче ел** **№2**

«Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлегенең
Яңа Кыязлы авылында
гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенең Яңа Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Яңа Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эш төрләренә тотуга ризамы”

**1. Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Яңа Кыязлы торак пунктындагы урамнарны төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

« ӘЙЕ» “ЮК"

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кыязлы авылы Чапаев урамы 20 нче йорт янында.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Дәүләтшин